**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"30" октябрь 2022 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Иске Шимбер торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер авылы территориясендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Иске Шимбер авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Иске Шимбер авылы территориясен чистарту, үлән чабу, агач һәм куак кисү, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- М. Җәлил урамындагы иске Шимбер авылы урамнарын ремонтлау һәм каплату (төзелеш материалларын сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Иске Шимбер авылы урамнарын грейдлау, кардан чистарту (эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Иске Шимбер авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Көек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.

Совет Нижнекуюкского сельского поселения
Түбән Көек авыл җирлеге советы